| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.12.2024 г.Казань № 540-124/кс-2024

«Ак Барс» кошчылык комплексы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен ташландык су агызуга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 13.10.2023 ел, №324-14/кс-2023 карары белән билгеләнгән озак сроклы тарифларны 2025 елга төгәлләштерү һәм Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 13.10.2023 ел, №324-14/кс-2023 карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы, «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә эшчәнлек алып баручы оешмаларның инвестиция һәм җитештерү программалары турында» 2013 елның 29 июлендәге 641 номерлы карарлары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә җайга салына торган тарифларны исәпләү буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 15.06.2010 ел, № 468 карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсе утырышының 17.12.2024 ел, №34-ПР беркетмәсе нигезендә, 2025 елга ташландык су агызуга озак сроклы тарифларга һәм җайга салынулы оешманың кирәкле тулаем керемenә төзәтмәләр кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Ак Барс» кошчылык комплексы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен ташландык су агызуга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Ак Барс» кошчылык комплексы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен ташландык су агызуга 2024-2028 елларга тарифлар билгеләү турында» 13.10.2023 ел, №324-14/кс-2023 карары белән билгеләнгән тарифларны 2025 елга төгәлләштереп, 1 нче кушымтаны яңа редакциядә (кушымтада) бәян итәргә.

2. Әлеге карарның 1 пункты белән төгәлләштерелгән тарифлар 2025 елның 1 гыйнварыннан 2025 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Ак Барс» кошчылык комплексы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен ташландык су агызуга 2024-2028 елларга тарифлар билгеләү турында» 13.10.2023 ел, №324-14/кс-2023 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ак Барс» кошчылык комплексы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен ташландык су агызуга 2024-2028 елларга тарифлар билгеләү һәм җитештерү программасын раслау турында»;

преамбулада «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салуы турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары белән» сүзләрен «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы, «Су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыручы оешмаларның инвестиция һәм җитештерү программалары турында» 2013 елның 29 июлендәге 641 номерлы карарлары белән» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 3.1-3.2 пунктлар өстәргә:

«3.1. Әлеге карарның 3 нче кушымтасы нигезендә «Ак Барс» кошчылык комплексы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен су агызу өлкәсендәге җитештерү программасын расларга.

3.2. Әлеге карарның 3.1 пункты белән расланган җитештерү программасы 2025 елның 1 гыйнварыннан 2028 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.»;

3 нче кушымта белән тулыландырырга (кушымта итеп бирелә).

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 13.10.2023 № 324-14/кс-2023 карарына 1 нче кушымта (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 17.12.2024 № 540-124/кс-2024 карары редакциясендә)

## Ташландык суларны агызуны гамәлгә ашыручы «Ак Барс» кошчылык комплексы» ҖЧҖ өчен 2024-2028 елларга ташландык су агызуга календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Ел | Су агызуга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|---|
| | Питрәч муниципаль районы | | |
| 1 | «Ак Барс» кошчылык комплексы» ҖЧҖ (тарифлар ӨХС исәпкә алмыйча күрсәтелә) | 01.01.2024 башлап 30.06.2024 кадәр | 17,37 |
| | | 01.07.2024 башлап 31.12.2024 кадәр | 19,88 |
| | | 01.01.2025 башлап 30.06.2025 кадәр | 19,88 |
| | | 01.07.2025 башлап 31.12.2025 кадәр | 21,04 |
| | | 01.01.2026 башлап 30.06.2026 кадәр | 19,56 |
| | | 01.07.2026 башлап 31.12.2026 кадәр | 20,94 |
| | | 01.01.2027 башлап 30.06.2027 кадәр | 20,94 |
| | | 01.07.2027 башлап 31.12.2027 кадәр | 21,00 |
| | | 01.01.2028 башлап 30.06.2028 кадәр | 21,00 |

| т/с | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Ел | Су агызуга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|---|
| | | 01.07.2028 башлап 31.12.2028 кадәр | 22,15 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф карарларын кабул
итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү
бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 13.10.2023 № 324-14/кс-2023 карарына 3 нче кушымта (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 17.12.2024 № 540-124/кс-2024 карары редакциясендә)

| **Оешманың җитештерү программасы** | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| **1 нче бүлек. Җитештерү программасы паспорты** | | | | | | |
| **Җайга салынулы оешма** | "Ак Барс" кошчылык комплексы" ҖЧҖ | | | | | |
| Урнашкан урыны | 422780, Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Ленино-Кокушкино авылы | | | | | |
| **Җайга салучы вәкаләтле орган** | Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты | | | | | |
| Урнашкан урыны | 420015, Татарстан Республикасы, Казан ш., Карл Маркс ур., 66 й. | | | | | |
| **Җитештерү программасын гамәлгә ашыру чоры** | башлана | 01.01.2025 | тәмамлана | 31.12.2028 | | |

| **2 нче бүлек. Су белән тәэмин итүнең һәм ташландык суларны агызуның үзәкләштерелгән системалары объектларын ремонтлау чаралары, эчә торган суның сыйфатын һәм агып төшүче суларны чистарту сыйфатын яхшыртуга юнәлдерелгән чаралар, энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру, шул исәптән транспортировкада су югалтуларын киметү чаралары исемлеге** | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| **№** | **Аталышы** | **Үлчәү берәмлеге** | **Гамәлгә ашыруга финанс ихтыяҗлары** | | | |
| | | | **2025** | **2026** | **2027** | **2028** |
| 1ВО - Су чыгаруга тариф | | | | | | |
| 1 | Агымдагы ремонт | мең сум | 120,70 | 124,64 | 128,33 | 132,12 |
| 2 | Капиталь ремонт | мең сум | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 |
| 3 | Башка чаралар, шул исәптән агып төшүче суларны чистарту сыйфатын яхшыртуга, энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлдерелгән чаралар | мең сум | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 |

| **3 нче бүлек. Су бирү күләме/Кабул ителгән су** | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1ВО - Су чыгаруга тариф | | | | | | |
| **№** | **Җитештерү эшчәнлеге күрсәткечләре** | **Үлчәү берәмлеге** | **Күрсәткеч зурлыгы** | | | |
| | | | **2025** | **2026** | **2027** | **2028** |
| 1 | Агынты суларны кабул итү, шул исәптән: | мең м3 | 141,89 | 141,89 | 141,89 | 141,89 |
| 2 | предприятиенең үз ихтыяҗлары | мең м3 | 125,00 | 125,00 | 125,00 | 125,00 |
| 3 | Хезмәтләрне җибәрү (гамәлгә ашыру), барысы да, шул исәптән: | мең м3 | 16,89 | 16,89 | 16,89 | 16,89 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 3.1 | бюджет оешмаларына | мең м3 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 |
| 3.2 | халыкка | мең м3 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 |
| 3.3 | башка кулланучылар | мең м3 | 16,89 | 16,89 | 16,89 | 16,89 |
| 3.4 | башка канализацияләрдән кабул ителгән агынты сулар | мең м3 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 |
| 4 | Агынты суларның исәпкә алынмаган агымы | мең м3 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 |
| 5 | Транспортлана торган агынты сулар күләме | мең м3 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 |
| 5.1 | Үз чистарту корылмалары аша үткәрелгән | мең м3 | 141,89 | 141,89 | 141,89 | 141,89 |
| 5.2 | Башка канализацияләргә тапшырылган агынты сулар | мең м3 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 |
| 6 | Чистарту корылмалары белән җиһазландырылмаган су чыгару торбалары аша үткәрелгән агынты су күләме | мең м3 | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 |
| **4 нче бүлек. Җитештерү программасын гамәлгә ашыру өчен кирәкле финанс ихтыяҗлары күләме** | | | | | | |
| **№** | **Күрсәткеч** | **Үлчәү берәмлеге** | **Күрсәткеч зурлыгы** | | | |
| | | | **2025** | **2026** | **2027** | **2028** |
| 1 | Җитештерү чыгымнары: | мең сум | 2 552,48 | 2 662,56 | 2 752,10 | 2 844,73 |
| 1.1 | Хезмәт өчен түләү һәм төп җитештерү персоналының социаль ихтыяҗларына түләү чыгымнары | мең сум | 1 667,07 | 1 721,37 | 1 772,32 | 1 824,78 |
| 2 | Ремонт чыгымнары: | мең сум | 120,70 | 124,64 | 128,33 | 132,12 |
| 3 | Административ чыгымнар: | мең сум | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 |
| 4 | Сату чыгымнары | мең сум | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 |
| 5 | Амортизация | мең сум | 229,59 | 229,59 | 229,59 | 229,59 |
| 6 | Аренда һәм концессия түләүләре, лизинг түләүләре | мең сум | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 |
| 7 | Салымнар һәм җыемнар | мең сум | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 |
| 8 | Норматив табыш: | мең сум | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 |
| 8.1 | Капиталь чыгымнар | мең сум | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 |
| 9 | Гарантияләүче оешманың исәпләмә эшкуарлык табышы | мең сум | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 |
| 10 | Узган чорларның алынмаган керемнәре / чыгымнары | мең сум | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 |
| 10.1 | Узган чорда тарифлар билгеләгәндә тарифларны җайга салу органы тарафыннан исәпкә алынмаган икътисадый нигезләнгән чыгымнар | мең сум | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 |
| 10.2 | Җайга салуның узган чорларында алынмаган керемнәр | мең сум | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 |
| 10.3 | Акча җитмәүне каплауга юнәлдерелгән заем акчаларына һәм үз акчаларына хезмәт күрсәтүгә бәйле чыгымнар | мең сум | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 |
| 11 | Җайга салуның узган чорларының икътисадый нигезләнмәгән керемнәре / чыгымнары | мең сум | 0,00 | 0,00 | 0,00 | 0,00 |
| 12 | Кирәкле тулай табыш | мең сум | 2 902,78 | 3 016,79 | 3 110,02 | 3 206,45 |
| **5 нче бүлек. Җитештерү программасы чараларын гамәлгә ашыру графигы** | | | | | | |
| **№** | **Чараның аталышы** | **План чоры** | | | | |

<table>
<tr><td>1</td><td>Су агызу челтәрләрен агымдагы ремонтлау</td><td colspan="5">2025-2028</td></tr>
<tr><td colspan="7">6 нчы бүлек. Су белән тәэмин итүнең һәм ташландык суларны агызуның үзәкләштерелгән системалары объектларының ышанычлылыгы, сыйфаты һәм энергетик нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең пландагы күрсәткечләре</td></tr>
<tr><td rowspan="2">№</td><td rowspan="2">Күрсәткеч</td><td rowspan="2">Үлчәү берәмлеге</td><td colspan="4">Күрсәткеч зурлыгы</td></tr>
<tr><td>2025</td><td>2026</td><td>2027</td><td>2028</td></tr>
<tr><td colspan="7">1ВО - Су чыгаруга тариф</td></tr>
<tr><td>1</td><td colspan="6">Агынты суларны чистарту сыйфаты күрсәткечләре</td></tr>
<tr><td>1.1</td><td>Дсвно – Үзәкләштерелгән гомуми агызу яисә көнкүреш су агызу системаларына ташлана торган агынты суларның гомуми күләмендә чистартылмый торган агынты су өлеше</td><td>%</td><td>0,00</td><td>0,00</td><td>0,00</td><td>0,00</td></tr>
<tr><td>1.2</td><td>Днн – Ташландык суларны ташлауның билгеләнгән нормативларына, ташландык суларны ташлау лимитларына туры килми торган агынты су пробаларының үзәкләштерелгән гомуми агызу (көнкүреш) системасы төренә карата исәпләнгән өлеше</td><td>%</td><td>0,00</td><td>0,00</td><td>0,00</td><td>0,00</td></tr>
<tr><td>2</td><td colspan="3">Су агызуның ышанычлылык һәм өзлексезлек күрсәткечләре</td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td>2.1</td><td>Пн – Канализация челтәренең озынлыгына исәпләгәндә аварияләрнең һәм чүп-чарларның чагыштырма саны</td><td>бер./км</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>3</td><td colspan="3">Энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре</td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td>3.1</td><td>Урост – технологик процесста кулланыла торган электр энергиясенең чагыштырма чыгымы</td><td>кВт*сәг/куб.м</td><td rowspan="2">0,846</td><td rowspan="2">0,846</td><td rowspan="2">0,846</td><td rowspan="2">0,846</td></tr>
<tr><td>3.2</td><td>Урп - ташландык суларны транспортировкалауның технологик процессында кулланыла торган электр энергиясенең ташландык сулар күләме берәмлегенә чагыштырма чыгымы</td><td>кВт*сәг/куб.м</td></tr>
<tr><td colspan="7">7 нче бүлек. Үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системалары объектларының ышанычлылыгы, сыйфаты һәм энергетик нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең пландагы күрсәткечләренең һәм житештерү программасын гамәлгә ашыру чыгымнарының аның гамәлдә булу чоры дәвамында үзгәреш динамикасын чагыштыру юлы белән гамәлгә ашырыла торган җитештерү программасының нәтиҗәлелеген исәпләү</td></tr>
<tr><td rowspan="2">№</td><td rowspan="2">Күрсәткеч</td><td rowspan="2">Үлчәү берәмлеге</td><td colspan="4">Планлаштырыла торган чор күрсәткече зурлыгы</td></tr>
<tr><td>2025</td><td>2026</td><td>2027</td><td>2028</td></tr>
<tr><td colspan="7">1ВО - Су чыгаруга тариф</td></tr>
<tr><td></td><td>Үзгәреш динамикасын чагыштыру</td><td>%</td><td colspan="4">Ышанычлылык, сыйфат һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең пландагы күрсәткечләре үзгәрешсез билгеләнә</td></tr>
<tr><td colspan="7">8 нче бүлек. Җайга салуның узган чорында җитештерү программасының үтәлеше турында хисап</td></tr>
<tr><td colspan="7">Җайга салуның узган чорында җитештерү программасының үтәлеше турындагы хисап оешманың 2023 елгы финанс-хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәләре турындагы хисабы составында бирелгән</td></tr>
<tr><td colspan="7">9 нчы бүлек. Абонентларга хезмәт күрсәтү сыйфатын яхшыртуга юнәлдерелгән чаралар</td></tr>
<tr><td>№</td><td colspan="6">Абонентларга хезмәт күрсәтү сыйфатын яхшыртуга юнәлдерелгән чаралар каралмаган</td></tr>
</table>